ПРОЕКТ

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча**
**төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә**
**дәүләт йомгаклау аттестациясе**

# ГЕОГРАФИЯ

буенча төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен
укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары
**кодификаторы**

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнде

# ГЕОГРАФИЯ
буенча төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен
укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары
**кодификаторы**

География буенча төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен эчтәлек элементлары һәм укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр кодификаторы (алга таба – кодификатор) контроль үлчәү материалларының (алга таба – КҮМ) төзелешен һәм эчтәлеген билгели торган документларның берсе булып тора. Кодификатор чыгарылыш сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәләренә һәрберсе аерым код белән бирелгән таләпләр һәм эчтәлекнең тикшерелә торган элементларының системага салынган исемлегеннән гыйбарәт.

Кодификатор Төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компоненты базасында (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2004 елның 5 мартындагы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми мәгариф дәүләт стандартлары федераль компонентын раслау турында» 1089 номерлы боерыгы) төзелде.

Кодификатор ике бүлектән тора:
– 1 бүлек. «ГЕОГРАФИЯ буенча төп дәүләт имтиханында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге»;
– 2 бүлек. «ГЕОГРАФИЯ буенча төп гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларның әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге».

Кодификаторга стандартның «Төп белем бирү программалары эчтәлегенең мәҗбүри минимумы» бүлегендә курсив белән бирелгән эчтәлек элементлары кертелмәгән: әлеге эчтәлек өйрәнелергә тиеш, ләкин стандартның «Чыгарылыш сыйныф укучысының әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр» бүлегенә кертелмәгән, ягъни контроль объекты булып тормый. Шулай ук кодификаторга чыгарылыш сыйныф укучысының әзерлеге дәрәҗәсенә ирешкән уңышларын дәүләт йомгаклау аттестациясе кысаларында тикшереп булмый торган таләпләр кертелмәде.

1. **ГЕОГРАФИЯ буенча төп дәүләт имтиханында тикшерелә торган эчтәлек элементлары исемлеге.**

Таблицаның беренче һәм икенче баганаларында уку курсы бүленгән эчтәлек блоклары кодлары күрсәтелгән. Беренче баганада бүлекләрнең (эре эчтәлекле блокларның) кодлары күрсәтелгән. Икенче баганада тикшерү биремнәре төзелә торган эчтәлек (тема) элементы коды күрсәтелгән.

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| Бүлекнең коды | Элементның коды | Имтихан барышында тикшереленә торган эчтәлек элементы |
|---|---|---|
| **1** | | **ГЕОГРАФИК МӘГЪЛҮМАТНЫҢ ЧЫГАНАГЫ** |
| | 1.1 | Географик модельләр: глобус, географик карта, урынның планы, аларның төп параметрлары һәм элементлары (масштаб, шартлы тамгалар, картографик сурәтләү ысуллары, градуслар челтәре) |
| | 1.2 | Танылган географик тикшеренүләр, ачышлар һәм сәяхәтләр |
| **2** | | **ҖИР ТАБИГАТЕ ҺӘМ КЕШЕ** |
| | 2.1 | Планета буларак җир. Форма, размерлары**,** Җирнең хәрәкәте |
| | 2.2 | Җир кабыгы һәм Җир шарының тышкы каты кабыгы (литосфера). Составы, төзелеше һәм үсеше. Җирнең өслеге: коры җир рельефы. Дөнья океаны төбе формас. Файдалы казылмалар, аларның урнашуының җир кабыгы һәм рельефның төзелешенә бәйле булуы. Җирнең минераль ресурслары, аларның төрләре һәм бәя. |
| | 2.3 | Гидросфера, аның составы һәм төзелеше. Дөнья океаны һәм аның өлешләре, атмосфера һәм коры җир белән үзара бәйләнеше. Коры җирнең өске һәм җир асты сулары. Бозлыклар һәм күпьеллык туңлыклар. Җирнең су ресурслары |
| | 2.4 | Атмосфера. Составы, төзелеше, циркуляция. Җир өстендә җылының һәм дымның таралышы. Һава торышы һәм климат. Һава торышы элементларын өйрәнү. |
| | 2.5 | Биосфера, аның башка геосфералар белән бәйләнеше.  Үсемлекләр һәм хайваннарның төрлелеге, аларның таралыш үзенчәлекләре. Туфрак катлам. Аерым бер табигый күренеш буларак туфрак.Төрле типтагы туфрак ясалуның шартлары. |
| | 2.6 | Җирнең географик тышчасы. Процессларның киңлекле зональлеге (широтная зональность) һәм югары пояслылыгы, цикллылыгы һәм ритмлылыгы. Табигый, табигый-хуҗалык территориаль комплекслар. |
| **3** | | **МАТЕРИКЛАР, ОКЕАННАР, ХАЛЫКЛАР ҺӘМ ИЛЛӘР** |
| | 3.1 | Җир планетасының бүгенге табигате. Материкларның һәм океан иңкүлекләренең килеп чыгышы. Җир йөзендә коры җир һәм океанның үзара нисбәте. |
| | 3.2 | Җир йөзе халкы. Җирдәге халык саны. Расалар, этнослар. |
| | 3.3 | Материклар һәм илләр. Африка, Австралия, Төньяк һәм Көньяк Америка, Антарктида, Евразия табигатенең төп сыйфатлары. Материклардагы халык. Табигый ресурслар һәм алардан файдалану. Табигатьнең кеше алып барган хуҗалык эшләре нәтиҗәсендә үзгәрүе Илләрнең күп төрлелеге, төп типлары |
| **4** | | **ТАБИГАТЬТӘН ФАЙДАЛАНУ һәм ГЕОЭКОЛОГИЯ** |
| | 4.1 | Кешеләр алып барган хуҗалык эшләренең табигатькә йогынтысы |
| | 4.2 | Табигатьтән файдалануның төп типлары |
| | 4.3 | Литосфера, гидросфера, атмосферадагы стихияле күренешләр |
| **5** | | **РОССИЯ ГЕОГРАФИЯСЕ** |
| | 5.1. | **Россиянең географик үзенчәлекләре** |

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

| | | |
|---|---|---|
| | 5.1.1 | Территория һәм акватория, диңгез һәм коры җир чикләре |
| | 5.1.2 | Сәгать пояслары |
| | 5.1.3 | Россиянең административ-территориаль төзелеше |
| | 5.2 | **Россиянең табигате** |
| | 5.2.1 | Рельефның геологик төзелеше һәм эре формаларының таралышы |
| | 5.2.2 | Климат типлары, аларны формалаштыруның факторлары, климатик пояслар. Климат һәм кешеләрнең хуҗалык эшчәнлеге. Күпьеллык туңлыклар |
| | 5.2.3 | Эчке сулар һәм су ресурслары, аларны илнең территориясендә урнаштыруның үзенчәлекләре |
| | 5.2.4 | Россия диңгезләренең табигый-хуҗалык аермалыклары |
| | 5.2.5 | Туфрак һәм туфрак ресурслары.Уңдырышлы туфракларны саклау чаралары. |
| | 5.2.6 | Россиядә үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы. Табигый зоналар. Югары пояслылык |
| | 5.3 | **Россия халкы** |
| | 5.3.1 | Халык саны, халыкның табигый хәрәкәте |
| | 5.3.2 | Халыкның җенес һәм яшь ягыннан составы |
| | 5.3.3 | Халыкның урнашуы. Урнашуның төп полосасы |
| | 5.3.4 | Миграциянең юнәлешләре һәм типлары |
| | 5.3.5 | Россия халыклары һәм төп диннәре |
| | 5.3.6 | Шәһәр һәм авыл халкы. Иң эре шәһәрләр |
| | 5.4 | **Россиянең хуҗалыгы** |
| | 5.4.1 | Россия хуҗалыгының тармак һәм территориаль төзелешенең үзенчәлеге |
| | 5.4.2 | Табигый-ресурс потенциалы һәм табигый ресурсларның иң мөһим территориаль бәйләнеше |
| | 5.4.3 | Промышленность тармаклары географиясе |
| | 5.4.4 | Авыл хуҗалыгы географиясе |
| | 5.4.5 | Транспортның иң мөһим төрләре географиясе |
| | 5.5 | **Россияне табигый-хуҗалык районнарга бүлү.** Аерым районнар һәм регионнарның географик үзенчәлекләре: Төньяк һәм Төньяк-Көнбатыш, Үзәк Россия, Идел буе, илнең Европа өлешенең көньягы, Урал, Себер һәм Ерак Көнчыгыш. Географик хәле. Регионнар, аларның табигый, кеше һәм хуҗалык потенциалы |
| | 5.6 | **Россия хәзерге дөньяда** |

## 2. География буенча төп гомуми белем бирүнең гомумбелем бирү программаларын үзләштергән укучыларның әзерлекләре дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге

Чыгарылыш укучылары әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге Төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компонентының «Чыгарылыш укучылары әзерлеге дәрәҗәсенә таләпләр» бүлеге нигезендә төзелде.

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

Таблицаның беренче ике баганасында таләпләр коды китерелгән, өченчесендә – чыгарылыш сыйныф укучыларының әлеге кодларга туры килә торган әзерлек дәрәҗәләренә таләпләр.

| Бүлек коды | Контроль үткәрелә торган таләпнең коды | Имтихан эше биремнәре аша тикшерелә торган таләпләр (осталыклар) |
|---|---|---|
| **1** | | **Белергә /аңларга:** |
| | 1.1 | Төп географик төшенчәләрне һәм терминнарны; |
| | 1.2 | план, глобус һәм географик картаның эчтәлеге, масштабы, картографик сурәтенең ысулы буенча аермасын; |
| | 1.3 | Бөек географик ачышлар һәм сәяхәтләрнең нәтиҗәләрен; |
| | 1.4 | Җир хәрәкәтенең географик нәтиҗәсе, геосферадагы географик күренешләр һәм процесслар, алар арасындагы бәйләнеш, кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә алардагы үзгәрешләрне |
| | 1.5 | географик зональлек һәм пояслыкны; |
| | 1.6 | материк һәм океаннарның табигатьләренең географик үзенчәлекләрен, шулай ук Җир халыклары географиясен; төрле территорияләр һәм акваторияләрнең хуҗалык ягыннан үзләштерелешендәге аермалылыкларны; географик урыны, табигый шартлары, ресурслары һәм илнең аерым регионнарындагы хуҗалыклары арасындагы бәйләнешләрне; |
| | 1.7 | географик урыны һәм Россия Федерациясенең административ-территориаль төзелешенең үзенчәлеген; аның табигатенең, халкының, төп хуҗалык тармаклары, табигый-хуҗалык зоналары һәм районнарының үзенчәлекләрен; |
| | 1.8 | геоэкологик проблемаларның локаль, региональ һәм глобаль дәрәҗәләрдә килеп чыгуының табигый һәм антропоген сәбәпләрен; табигатьне һәм кешеләрне стихияле табигый һәм техноген күренешләрдән саклау буенча чараларны |
| **2** | | **Осталыклары булырга тиеш:** |
| | 2.1 | урында, планда һәм картада ераклыкны, юнәлешне, нокталар биеклеген; географик координаталарны һәм географик объектларның урыннарын билгели белергә; |
| | 2.2 | географик объектларның һәм күренешләрнең мөһим билгеләрен аерып ала (таный) белергә; |
| | 2.3 | географик объектлар һәм күренешләрнең мөһим билгеләрен сурәтли белергә; |
| | 2.4 | географик объектлар һәм күренешләрнең мөһим билгеләрен аңлатырга; |
| | 2.5 | төрле территорияләрнең кыскача географик характеристикасын төзергә; |

| | | |
|---|---|---|
| | 2.6 | табигый ресурслар, аларны файдалану һәм саклау, яшәү мохите йогынтысында халыкларның мәдәни-көнкүреш үзенчәлекләре формалашуга; иң эре чимал һәм ягулык-энергетика базалары, районнары һәм иң мөһим саналган продукция төрләрен җитештерү, төп коммуникацияләр һәм аларның челтәрләре, Россиянең, шулай ук дөньяның эре регионнары һәм илләре арасындагы эчке һәм тышкы икътисади бәйләнешләре турында мисаллар китерә белергә |
| | 2.7 | төрле чыганаклардан географик объект һәм күренешләрне җирнең төрле территорияләрен, аларның табигый һәм кеше ресурслары белән тәэмин ителеше, хуҗалык потенциалы, экологик мәсьәләләрне өйрәнү өчен мәгълүмат таба белергә |
| | 2.8 | Җирнең төрле территорияләрендәге географик объектларны һәм күренешләрне, аларның табигый һәм кеше ресурслары белән тәэмин ителеше, хуҗалык потенциалы, экологик мәсьәләләрне өйрәнү өчен кирәкле мәгълүматны анализларга; |
| | 2.9 | үлчәүләрнең нәтиҗәләрен төрле формада бирергә, шуның нигезендә эмпирик бәйләнешне чагылдырырга |
| **3** | **Алынган белемнәрне һәм осталыкларны гамәли эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта түбәндәге очракларда файдалана белергә тиешләр:** | |
| | 3.1 | вакыт поясын ачыклаганда; |
| | 3.2. | төрле эчтәлекле карталарны укыганда; |
| | 3.3. | тирә-як мохитнең сыйфатын билгеләү, аны файдалануга юнәлдерелгән гамәли мәсьәләләрне чишкәндә. |

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте